ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

от 30.11.2020 г. Казань № 322-133/кс-2020

2021 елга «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ) өчен, әлеге карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
30.11.2020 № 322-133/кс-2020
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2021 елга эчә торган суга, техник суга һәм су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Биектау коммуналь челтәрләре» АЖ, технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | | | | |
| 1.1 | Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре кулланучылары | | | | | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән)* | 21,94 | 22,80 | | | 26,74 | 27,70 |
| 1.1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 18,28 | 19,00 | | | 22,28 | 23,08 |
| 1.2 | Дачный авыл җирлеге кулланучылары | | | | | | |
| 1.2.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 30,07 | 30,86 | | | 34,51 | 35,16 |
| 1.2.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 25,06 | 25,72 | | | 28,76 | 29,30 |
| 1.3 | Чернышевка авыл җирлеге кулланучылары | | | | | | |
| 1.3.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 33,02 | 34,24 | | | 47,86 | 49,76 |

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| 1.3.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 27,52 | 28,53 | | | 39,88 | 41,47 |
| 1.4 | Дөбъяз, Семиозерка һәм Усад авыл җирлекләре кулланучылары | | | | | | |
| 1.4.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | 31,49 | 32,51 | | |
| 1.4.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | 26,24 | 27,09 | | |
| 1.5 | Алан-Бәксәр, Каенлык, Олы Битаман, Олы Кавал, Казаклар, Алат, Суыксу авыл җирлекләре кулланучылары | | | | | | |
| 1.5.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 33,02 | 34,24 | | | | |
| 1.5.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 27,52 | 28,53 | | | | |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге